КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 декабрь г.Казань № 1160

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең төбәк системасын бәяләүне үткәрүне оештыру тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең төбәк системасын бәяләүне үткәрүне оештыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең төбәк системасын бәяләүне үткәрү эшен яраштырырга;

Татарстан Республикасында инвалидларны, шул исәптән инвалид балаларны тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең төбәк системасын бәяләүгә методик ярдәм күрсәтергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин